| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2024 Балык Бистәсе штп. № 267пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.07.2022 №143пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеме белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында,

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше ,Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик һәм мәгълүмати-технологик тәкъдимнәр турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 02.08.2024 номерлы боерыгы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.07.2022 №143пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеме белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) II бүлектә 2 пунктны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификацион дәрәҗә | Вазифаның атамасы | Айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем " |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификацион дәрәҗә | Методист | - | - | 18405,0 |
| Дүртенче квалификацион дәрәҗә | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификацион дәрәҗә | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 18481,0<br>18550,0 |

1.2) 3.3 пунктының 10 абзацында "Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе", "Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен" күкрәк билгесе", "Яшь мөгаллим" күкрәк билгесен, "Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы" билгесен, "Мактаулы остаз" билгесе дигән сүзләр белән тулыландырырга.»;

1.3) нигезләмәгә кушымтада 1.8 һәм 1.9 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре.

1.9. Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре»;

1.4) нигезләмәгә кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 1.10 һәм 1.11 пунктчалары белән өстәргә:

«1.10. Мәгариф отличнигы;

1.10. Россия Федерациясенең мактаулы тәрбия һәм мәгариф хезмәткәре.».

2. Әлеге карар үз гамәлен 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы И.М. Садыйковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов